ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2022 Олы Кайбыч ав. № 517

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә ярдәм итү максатларында Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләргә һәм затларга, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарга, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага кертелгән гражданнар, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә чараларны билгеләргә:

1.1. Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукы бирү.

1.2. Көндезге мәктәп яны лагерьларында ата-аналар взносын түләүдән азат итү.

1.3. Балаларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программалары буенча дәресләргә (түгәрәкләргә, секцияләргә һәм башка шундый дәресләргә) түләүсез йөрү.

1.4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты буйсынуындагы спорт оешмаларына бушлай йөрү, шулай ук чаңгы һәм тимераякларны бушлай прокатка бирү.

2. Ярдәм чаралары муниципаль учреждение җитәкчесе исеменә язмача гариза, хәрби комиссариат белешмәсе, бала туу турында таныклык нигезендә бирелә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

5. 1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров